**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Школьная, д.8, с.Карамышево,
423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 8 йорт, Кармыш авылы,
423119

тел./факс (84396) 4-22-23 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

№ 58 от 12 март 2018 ел

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
## КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 ноябрендәге 63 номерлы «Җир салымы турында » карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы прокурорының 2018 елның 9 февралендәге 164-р номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.Кармыш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 5 ноябрендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү (2014 елның 12 ноябрендәге 76 номерлы һәм 05.05.2015 ел, № 110) «Салым базасын киметү хокукын раслый торган документларны салым түләүчеләр тарафыннан тапшыру тәртибе һәм сроклары» 6 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүчеләр-салым ташламаларына хокуклы физик затлар, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым чигерүе рәвешендә дә, салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы. Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслау РФ Салым Кодексының 361.1 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла. Салым түләүчеләр салым декларациясе тапшыру өчен билгеләнгән вакытта - шәхси эшмәкәр булган физик затлар ».

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлек Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә

Башлык, Кармыш авыл җирлеге Советы Рәисе М.М.Миншин